РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Учаллинского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района
ул. Советская, д.51, Азнакаевский район,
с.Учалле, 423317

тел./факс (885592)36-8-32
E-mail: Uchal.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге
БАШЛЫГЫ
Совет ур., 51 нче йорт, Азнакай районы Үчәлле авылы, 423317

тел./факс (885592)36-8-32
E-mail: Uchal.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«08» сентябрь, 2025 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Үчәлле торак пунктында «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Үчәлле авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2024 елның 18 октябрендәге 2 номерлы карарына, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең Үчәлле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 18 октябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге Уставының 15.1 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Башлыгы карар бирә:

1. Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Үчәлле авылы, Совет ур., 51 йорт адресы буенча урнашкан Үчәлле авылы мәдәният йорты бинасында 2025 елның 19 сентябрендә 10.00 сәгатькә 2024 елның 18 октябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2024 елның 18 октябрендәге 2 нче номерлы «2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Үчәлле торак пунктында теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2024 елның 18 октябрендәге 1нче номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында», 2024 елның 18 октябрендәге 2 нче номерлы «2025 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында» карарларындагы түбәндәгечә бәян ителгән чараны:

«- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү ,ремонтлау, карап тоту (Яшьләр урамындагы, Тукай урамындагы асфальт-бетон юлның чокырларын ремонтлау);»

түбәндәге редакциядә раслау белән килешәсезме?:

«- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамы); »

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Азнакай муниципаль районының рәсми сайты»нда http://aznakaevo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Башлык Г.М.Төхвәтуллина